# Эшнең тәмамлануын белдерүче(выражающие завершение действия) аналитик фигыльләр:

- *Эшләп бетерде(доделал), кайтып җитте(доехал), язып чыкты(дописал), сөйләшеп алдык(поговорили), матурланып киттеләр(похорошели).*

Җөмләләрне тәрҗемә итегез һәм кушма фигыль хәбәрләрне язып алыгыз.

1.Без бу фильмны карап бетермәдек.2. Тамаша вакытында башланып китте. 3. Театрда очрашкач, без танышыбыз белән тиз генә  сөйләшеп алдык.4. Ул тиз арада бу пьеса  белән танышып чыкты. 5. Алар тугызынчы катка менеп җиттеләр.

# 4.Җөмләләрне татарча әйтегез.

1.Вернитесь до семи часов. 2. Я закончу эту работу через 20 минут.3. Вы дописали новые слова? 4.Мы быстро поговорили о последних новостях.5. Все собрались, и праздник начался. 6.Он выбежал из комнаты.7.В конце месяца дни потеплели.

## 6. Кирәкле фигыльләрне куеп, җөмләләрне языгыз.

1.”Банкрот” пьесасын Галиәсгар Камал ... 2.”Алтынчәч” операсында төп рольне Зилә Сөнгатуллина ... .3. Татар театрында Туфан Миңнуллинның “Әниләр һәм бәбиләр” спектаклен ... .4.Ял сәгатьләрендә әнием Рөстәм Яхин романсларын тыңларга ... . 5.Мин буш вакытымны файдалы үткәрергә ...
6. Дустым теннис белән ... .

7.Сораулар куеп, сүзләрне укыгыз.

- ...? Оештыручылар .
- ...? Башкарырга.
- ...? Багышлый.
- ...? Иҗат.
- ...? Уйнады.
- ...? Әсәрләр.
- ...? Иҗади.
- ...? Тамашалар.
- ...? Биючеләр.
- ...? Ял

8.Нокталар урынына театр исемнәрен куеп, җөмләләрне языгыз.

Мин ... театрына барды... .

Син... театрына барды... .

Без ... театрына барды... .

Сез ... театрына барды... .

9.Фразеологизмнарны укыгыз һәм берничәсе белән җөмлә төзеп языгыз.

- Күз ачып йомганчы( в мгновение ока);

бер минут эчендә(в одну минуту); хан заманыннан(испокон веков), шушы көннәрдә(со дня на день); онытканда бер( время от времени), беренче чиратта

(в первую очередь)